КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 сентябрь г.Казань № 937

Россия Федерациясе Музей фонды торышын төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясе Музей фонды һәм Россия Федерациясендә музейлар турында» 1996 елның 26 маендагы 54-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында» 2010 елның 14 октябрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Россия Федерациясе Музей фонды торышын төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәне расларга.
2. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:
Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт өлеше торышын дәүләт контролендә тотуны оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2017 ел, 10 октябрь, 779 нчы карары;
«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт өлеше торышын дәүләт контролендә тотуны оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2017 ел, 10 октябрь, 779 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт өлеше торышын дәүләт контролендә тотуны оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә

үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 12 октябрь, 922 нче карары.

3. Бу карар имза куелган көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин